РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Центральная, 7,д. Караталга, 422834
тел/факс. (8-834-77)30-4-39
ОКПО 93064642 , ОГРН 1061672003425
ИНН/КПП 1622004595/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урамы, 7, Каратал авылы, 422834,
тел/факс. (8-834-77)30-4-39
ОКПО 93064642, ОГРН 1061672003425
ИНН/КПП 1622004595/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 ел , 22 сентябрь** **№ 6**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар кыла.

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 500 сум үзара салым кертү белән билгеләнгән, һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

*** - җирлек торак пунктлары чикләрендә территорияләрне төзекләндерүне кагыйдәләр нигезендә оештыру;**
*** - җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**
*** - Күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру;**

*** - җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;**
*** - җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү;**
*** - коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыру.”**

2. Әлеге карарны түбәндге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Караталга авылы, Күпер урамы, 5;
3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14;
шулай ук «Волжские зори» («Идел таннары») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, «Идел таннары» район газетасының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе ________________И.Х.Сәгдиев